РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
ЧЕРКИ-КИЛЬДУРАЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДУРАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«20» октябрь 2020ел

№ 4-2

ТР Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы һәм муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлеге Советының 2019 елның 27 февралендәге 68-1 номерлы карары белән расланган (12.02.2020 ел, № 87-1 карар редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 бүлек:

7.3 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрне, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелә торган очраклардан тыш;»;

1.2. 30 бүлек:

30.1 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персоналаштырылган) исәпкә алу турында, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру;».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районы Килдураз
авыл җирлеге башлыгы З.З. Ахатов